# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“16” ноябрь 2019 ел. № 01

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә «Сез 2020 елда Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Иске Шимбер авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту һәм кисү;

2) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

-Иске Шимбер авылында янгын гидрантын урнаштыру өчен төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү

3) Җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Иске Шимбер авылының урам юлларын ремонтлау өчен материаллар алу һәм хезмәтләр өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 32 (утыз ике) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 28 (егерме сигез) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 28 (егерме сигез) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2020 елда Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: -

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Иске Шимбер авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту һәм кисү;

2) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

-Иске Шимбер авылында янгын гидрантын урнаштыру өчен төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү

3) Җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Иске Шимбер авылының урам юлларын ремонтлау өчен материаллар алу һәм хезмәтләр өчен түләү”мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Мөхәммәтгалиев Ф.Т.